**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 15 гыйнвар № 9

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 12 апрель, 234 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРЪ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 12 апрель, 234 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәдә:

1.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт комитеты урнашкан урын (юридик адрес): 420015, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Максим Горький урамы, 19 нчы йорт»;

3.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Дәүләт комитеты үзенең төп функциясе – туризм өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыру өчен (04.09 <*>) җавап бирә, шул исәптән:

туристлык эшчәнлеген җайга сала торган Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокук актларын эшләү һәм тормышка ашыру (04.09.01 <*>).»;

3.2 нче пунктның унтугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«физкультура һәм спорт өлкәсендә идарә итү (04.04<*>)»;

4.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау өчен Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә Дәүләт комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча телдән һәм язма рәвештә хокукый консультация бирү рәвешендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтә;

федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокук актлары белән билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә социаль ярдәмгә һәм социаль

яклауга мохтаж гражданнарга гаризалар, шикаятьләр, үтенечләр һәм хокукый характердагы башка документлар тутыру рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә һәм судларда, дәүләт органнарында һәм муниципаль органнарда, оешмаларда гражданнар мәнфәгатьләрен яклый.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты структурасында «Җитәкче» һәм «Җитәкче урынбасары» сүзләрен тиешенчә «Рәис» һәм «Рәис урынбасары» сүзләренә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\9.doc